**СОВЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422610 г.Лаишево,
ул. Первомайская, д.39
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**

422610 Лаеш ш.,
Беренче май урамы, 39 нчы йорт,
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

**2019 елның 21 февраленнән** **№3-КС**

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының жирле үзидарә органнары законнары һәм муниципаль норматив хокукый актлары үзгәрешенә мониторинг үткәрү турында Кагыйдәне раслау хакында**

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының җирле үзидарә органнары тарафыннан кабул ителгән муниципаль норматив хокукый акилар һәм законнар үзгәрешенә мониторинг үткәрү буенча җирле үзидарә органнары эшен камилләштерү максатыннан, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Уставына нигезләнеп, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль район Советы карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының җирле үзидарә органнары законнары һәм муниципаль норматив хокукый актлары үзгәрешенә мониторинг үткәрү турында Кагыйдәне расларга.

2. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының җирле үзидарә органнарына:

-үзләренең норма иҗат итү эшчәнлегендә әлеге карарның 1 пунктында расланган Кагыйдәгә нигезләнергә;

-күрсәтелгән Кагыйдәне үтәү өчен җаваплы затларны билгеләргә;

-җаваплы зат итеп билгеләнгән муниципаль хезмәткәрләрнең вазифаи инструкцияләренә шуңа туры килүче үзгәрешләр кертергә.

3. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы составына керүче җирлекләрнең җирле үзидарә органнарына муниципаль норматив хокукый актларының законнарга, муниципаль берәмлекләр уставларына ярашлылыгын системалы контрольдә тотуны тормышка ашыру мониторингын үткәрүне тәэмин итүче муниципаль норматив хокукый актлар кабул итүне тәкъдим итәргә.

4. Бу карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми сайтында Интернетның мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча бастырырга (халыкка чыгарырга) һәм Лаеш муниципаль районының http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернетның мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

5. Әлеге карар үтәлешенә контрольлек итүне Лаеш муниципаль район Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирле үзидарә органнары белән үзара бәйләнеш буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

**Башлык – муниципаль район**
**Советы рәисе** **М.П. Афанасьев**